МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__26.10.2023______ Казан шәһәре №__195-ОД_________

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы үзенә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә «2014-2025 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2015-2025 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы чараларын 2022-2025 елларда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 мартындагы 47-ОД номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы үзенә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә «2014-2025 елларга Татарстан

Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2015-2025 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы чараларын 2022-2025 елларда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 21 мартындагы 47-ОД номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2022 елның 6 декабрендәге 255-ОД номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның атамасында:

«2022 – 2025» сүзләрен «2022 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

«2015 – 2025» сүзләрен «2015 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

«2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

Боерыкның преамбуласында:

«2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

Боерыкның 1 пунктында:

«2022 – 2025» сүзләрен «2022 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

«2015 – 2025» сүзләрен «2015 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

«2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы үзенә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә «2014-2025 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2015-2025 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы чараларын 2022-2025 елларда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

Тәртип атамасында:

«2022 – 2025» сүзләрен «2022 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

«2015 – 2025» сүзләрен «2015 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

«2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

Тәртипнең 1 нче пунктында:

«2022 – 2025» сүзләрен «2022 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

«2015 – 2025» сүзләрен «2015 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

«2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

Тәртипнең 2 нче пунктының икенче абзацында:

«2015 – 2025» сүзләрен «2015 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

«2014 – 2025 елларга» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

Тәртипнең 2 нче пунктының дүртенче абзацында:

«2022 – 2025» сүзләрен «2022 – 2024» сүзләре белән алмаштырырга;

Тәртипнең 4 нче пунктында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чаралар программасы;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алу өчен гариза тапшыру көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага салым органы белешмәсе, ул Учреждениедә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар буенча үтәлмәгән бурычның булмавын расларга тиеш;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза бирелгән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага булган торышында Учреждениенең Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиешле, түләү вакыты узган бурычларның, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрнең, бюджет инвестицияләренең булмавы турында җитәкче һәм баш хисапчы тарафыннан имзаланган, Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелгән белешмә, Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерү, аварияле (гадәттән тыш) хәлне булдырмый калу, аварияле (гадәттән тыш) хәл барлыкка килгән очракта аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкару, законлы көченә кергән суд актлары, башкару документлары буенча бурычларны каплау очракларыннан тыш, шулай ук федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән башка очраклардан тыш.»;

Тәртипнең 5 нче пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Гариза кабул ителгән көнне Гамәлгә куючы тарафыннан теркәлә.»;

Тәртипнең 8 нче пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Гариза бирү көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага Учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

Тәртипнең III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Учреждение Гамәлгә куючыга түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

квартал саен, хисап кварталыннан соңгы өч эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидияләр чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап;

хисап елының соңгы аеның 25 нче көненнән дә соңга калмыйча, килешүнең үтәлеше турында йомгаклау хисабы, ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшырып.

Хисапларның формалары килешүдә билгеләнә.

Тапшырыла торган хисаплылык һәм кушымта итеп бирелә торган документлар аңлаешлы итеп бастырылган булырга тиеш.

Учреждение мөһере (булган очракта) белән беркетелгән һәм вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган яисә Учреждение җитәкчесе тарафыннан үз кулы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.»;

Тәртипкә 1 нче кушымтаны әлеге боерыкка 1 нче кушымтадагы редакциядә бәян итәргә;

Тәртипкә 2 нче һәм 3 нче кушымталарны төшереп калдырырга.

2. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары Р.М.Карповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В.Коробченко

_______________ № ________
боерыкка 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы үзенә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә «2014-2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацияле икътисады» дәүләт программасының «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру» ярдәмче программасы чараларын 2022-2024 елларда гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымта
№ ______________ «___» ______ 2023 ел.

Нәтиҗә күрсәткечләре

| т/с | Нәтиҗәнең (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторының) атамасы, үлчәү берәмлеге | Нәтиҗә (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы) күрсәткече | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1 | Мәгълүматлаштырылган предприятиеләр саны, елына кимендә берәмлек | 300 | 700 | 300 |
| 2 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә уздырылган илкүләм проектны гамәлгә ашыру турында киңәшмәләр саны, елына кимендә, берәмлек | 15 | 15 | 15 |
| 3 | Елына бердән дә ким булмаган күләмдә уздырылган семинарлар, утырышлар, «түгәрәк өстәлләр» саны | 3 | 3 | 3 |
| 4 | Ppt.tatarstan.ru сайтына керүчеләр саны, | 20 | 25 | 20 |

| т/с | Нәтиҗәнең (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторының) атамасы, үлчәү берәмлеге | Нәтиҗә (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы) күрсәткече | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2022 | 2023 | 2024 |
| | елына кимендә мең кеше | | | |
| 5 | Үткәрелгән бәйгеләр саны, елына берәмлек | 1 | 1 | 1 |
| 6 | Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру инструментларына өйрәнгән предприятиеләр хезмәткәрләре һәм төбәк командалары вәкилләре саны, кимендә кеше,  арта бара торган нәтиҗәсендә | 2 625 | 3 313 | 3 974 |
| 7 | Региональ идарәдә (ТР ТКҮ тарафыннан) хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру инструментларына укыган предприятиеләр хезмәткәрләре саны, кимендә кеше, арта бара торган нәтиҗәсендә | 1 632 | 2 238 | 2 888 |
| 8 | Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында катнашучы предприятиеләрнең, шулай ук башкарма хакимият органнарының укытылган хезмәткәрләре саны, кимендә кеше, арта бара торган нәтиҗәсендә | 216 | 216 | 216 |
| 9 | Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру инструментларына өйрәнгән төбәк командалары вәкилләре саны, кеше, арта бара торган нәтиҗәсендә | 60 | 75 | 86 |
| 10 | Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру өчен идарә итү күнекмәләре программасы буенча укытылган җитәкчеләр саны, мең кеше (арта бара торган нәтиҗәсендә) | 0,219 | 0,239 | 0,24 |
| 11 | Төбәк идарәсендә илкүләм проектта катнаша торган предприятиеләрдә сакчыл җитештерү буенча әзерләнгән инструкторлар саны (ТР ТКҮ белән), елына кеше | 88 | 98 | 44 |
| 12 | Җитештерү һәм офис процесслары фабрикалары аша укытылган югары уку йортлары, урта һөнәри белем бирү йортлары, мәктәпләр һәм башка дәүләт белем йортлары укучылары саны, елына кеше | 16 | 16 | 16 |

| т/с | Нәтиҗәнең (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторының) атамасы, үлчәү берәмлеге | Нәтиҗә (ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы) күрсәткече | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2022 | 2023 | 2024 |
| 13 | Предприятиеләрнең региональ компетенцияләр үзәкләре эше белән канәгать булуы (әлеге үзәкләре эшеннән канәгать булган предприятиеләр өлеше), ким дигәндә, процент | 70 | 80 | 80 |
| 14 | Адреслы ярдәм алу аша илкүләм проектка җәлеп ителгән предприятиеләр саны, кимендә берәмлек, арта бара торган нәтиҗәсендә | 161 | 204 | 248 |
| 15 | Илкүләм проект чараларын мөстәкыйль кертә торган катнашучы предприятиеләр саны, кимендә берәмлек, арта бара торган нәтиҗәсендә | 22 | 22 | 22 |
| 16 | Региональ идарәдә (ТР ТКҮ белән) илкүләм проект чараларын гамәлгә ашыручы предприятиеләр саны, кимендә берәмлек, арта бара торган нәтиҗә белән, шул исәптән | 94 | 134 | 178 |
| 17 | Эшче төркемнәр төзегән предприятиеләр саны, кимендә берәмлек, арта баручы нәтиҗә белән | 94 | 134 | 178 |
| 17.1 | Илкүләм проектта катнашучы, диагностика уздырылган предприятиеләр саны, кимендә берәмлек, арта баручы нәтиҗә белән | 94 | 134 | 178 |
| 17.2 | Илкүләм проектта катнашучы предприятиеләр тарафыннан максатчан күрсәткечләргә ирешү турында ТР ТКҮ хисаплары саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 |
| 18 | Проектта катнашуның өч елы дәвамында федераль һәм төбәк идарәсе астында илкүләм проект чараларын гамәлгә кертүче катнашучы-предприятиеләрдә ел саен 5 процентлы хезмәт җитештерүчәнлеге үсешенә ирешкән предприятиеләр өлеше, процент | 50 | 50 | 50 |